**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Арча муниципаль районы**
**Урта Курса авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

422024, Арча муниципаль районы
Урта Курса авылы, Молодежная урамы, 13
тел. 53-4-32

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Арский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Среднекорсинского сельского поселения**

422024, Арский муниципальный район
д.Средняя Корса, ул.Молодежная 13
тел. 53-4-32

**КАРАР**

**« 09 » апреля 2020 ел** **№ 11**

**"Махсус инвестиция контракты төзү тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында**

"Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында" 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында" 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында" 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм инвестицияләр җәлеп итү максатыннан, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә инвестиция контрактлары төзү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлеге
башкарма комитетының
09 апрель 2020 ел, N 11
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә махсус инвестиция контракты төзү тәртибе турында Нигезләмә**

1. Әлеге Тәртип "Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында" 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә инвесторга сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне стимуллаштыруның аерым чараларын күрсәтү максатларында махсус инвестиция контракты төзү тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә инвестиция контрактлары төзү шартларын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

- инвестиция контракты - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм инвестор арасында шартнамә;

- инвестицияләү объекты - инвестор инвестиция контрактын гамәлгә ашыру кысаларында үз һәм (яки) җәлеп ителгән акчалар бирә торган күчемсез милек объекты (бина, корылма, төзелеш);

- инвестор - инвестиция конкурсында җиңеп, инвестицион контрактлар төзү хокукына ия булган, инвестиция контракты төзегән һәм үз акчалары хисабына, финанс ресурсларын яки заем акчаларын җәлеп итеп инвестиция проектын финанслауны (финанслашуны) тәэмин итүче физик яки юридик зат.

2. Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә махсус инвестицион контракт үз көче белән яки башка затларны җәлеп итеп сәнәгать продукциясе җитештерүне булдыру һәм (яки) үзләштерү максатында махсус инвестиция контрактында каралган йөкләмәләрне үз өстенә алган юридик зат яисә шәхси эшмәкәр белән төзелә (алга таба - инвестор, җәлеп ителгән зат, инвестицњ проекты).

3. Махсус инвестиция контрактының яклары булып махсус инвестиция контрактының ягы булган инвесторга һәм (яки) махсус инвестиция контрактында күрсәтелгән башка затларга карата сәнәгать өлкәсендә муниципаль хокукый актларда каралган эшчәнлекне стимуллаштыру чараларын гамәлгә ашыру очрагында, Татарстан Республикасының Арча муниципаль районы Урта Курса Башкарма комитеты тора.

4. Махсус инвестицион контракт төзелергә мөмкин булган инвестиция проектларын карап тикшерү һәм сайлап алу Арча муниципаль районы башлыгының 2014 елның 10 апрелендәге 61 номерлы "Арча муниципаль районының Инвестиция советын төзү турында" карары белән төзелгән Арча муниципаль районы инвестиция советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Махсус инвестиция контракты Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең инвестиция проектлары гамәлгә ашырыла торган сәнәгать өлкәсендә куелган бурычларга һәм муниципаль программалар индикаторларына һәм максатчан күрсәткечләренә ирешү максатларында инвестиция проектларына карата гамәлгә ашырыла.

6. Махсус инвестиция контрактының типлаштырылган формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Сәнәгатьнең аерым тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында" 2015 елның 16 июлендәге 708 номерлы карары белән расланган.

7. Махсус инвестиция контракты, инвестиция проектының бизнес-планы нигезендә проектның операция табышына чыгу вакытына тигез рәвештә 5 елга арттырылып, 10 елдан да артмаган срокка төзелә.

8. Инвестиция контракты төзү белән кызыксынган физик яки юридик зат Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса Башкарма комитетына түбәндәге документлар җибәрә:

8.1. Юридик зат булган инвесторлар өчен:

- билгеләнгән форма буенча гариза (1 нче кушымта);

- инвестиция программасы (инвестор аны 3 нче кушымта нигезендәге үрнәк буенча мөстәкыйль тутыра);

- барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән гамәлгә кую документларының тиешлечә расланган күчермәләре;

- инвесторны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелүе турында таныклык күчермәсе;

- гариза тапшырган датага салым органы тамгасы белән оешманың бухгалтерлык балансының инвестор раслаган күчермәсе;

-бюджетка мәҗбүри түләүләр һәм салым түләү буенча бурычлар булмавын раслаучы документ;

- инвесторны гамәлдән чыгару яки үзгәртеп коруның яисә инвесторның банкротлык стадиясендә булуын раслаучы документлар (ЕГРЮЛдан өземтә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды карары);

- инвестор исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслаучы документ, кирәк булган очракта;

8.2. Физик зат булган инвестор өчен (шул исәптән шәхси эшмәкәрләргә):

- билгеләнгән форма буенча гариза (2 нче кушымта);

- инвестиция программасы (инвестор аны 3 нче кушымта нигезендәге үрнәк буенча мөстәкыйль рәвештә тутыра).

- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;

- шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (шәхси эшмәкәр булганда яки булса);

- бюджетка мәҗбүри түләүләр һәм салым түләү буенча бурычлар булмавын раслаучы документ;

- инвесторның банкротлык стадиясендә булмавын раслаучы документ;

- конкурста катнашучы исеменнән гамәлләр башкаруга затның вәкаләтләрен раслаучы документ, кирәк булган очракта (ЕГРИПтан өземтә).

9. Сәнәгать продукциясен җитештерү төзелә яисә модернизацияләнә торган махсус инвестиция контракты төзү өчен, дәгъва кылучы әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза составында сәнәгать җитештерүен булдыруны һәм модернизацияләүне, эш урыннарын булдыруны, сәнәгый продукция эшләп чыгаруның булдырылган (модернизацияләнгән) куәтләрендә үзләштерүне һәм инвестиция характерындагы чыгымнарны мәҗбүри рәвештә гамәлгә ашыруны раслый торган документлар тапшыра.

9.1. Яңа җитештерү егәрлекләрен булдыру өчен җир кишәрлекләрен сатып алу яки озак вакытка арендалауга (инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлеге инвестор яки җәлеп ителгән затлар милкендә булган очраклардан тыш);

9.2. Проект документларын эшләүгә;

9.3. Җитештерү биналарын һәм корылмаларын төзүгә яки реконструкцияләүгә рөхсәт;

9.4. Төп чараларны сатып алу, төзү, китерү, расконсервацияләү һәм модернизацияләүгә (инвестиция проектыны гамәлгә ашыру барышында сатып алына торган җиһазларның минималь өлеше модернизацияләнә торган һәм (яки) расконсервацияләнә торган җиһаз бәясенең кимендә 25 процентын тәшкил итә), шул

исәптән таможня пошлиналары һәм таможня җыемнары, шулай ук төзелеш-монтаж һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә.

9.5. Әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган документлар булып инвестиция проектының бизнес-планы, инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында алдан килешү (килешүләр) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында алдан төзелгән шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе тора. Алар инвестиция проектын гамәлгә ашыруда өченче затларның катнашу тәртибен билгели (булганда).

10. Дәгъва кылучы, иң яхшы уңайлы технологияләр кертелә торган махсус инвестиция контракты төзү өчен, гариза белән бергә "Әйләнә-тирәлекне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә иң яхшы уңайлы технологияләрне гамәлгә кертүне раслаучы документлар тапшыра:

10.1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән килештерелгән әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары планы (II һәм III категорияле объектлар өчен);

10.2. "Әйләнә-тирәлекне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән ведомствоара комиссия тарафыннан хупланган экологик нәтиҗәлелекне күтәрү программасы (I категорияле объектлар өчен);

10.3. Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында инвестиция килешүе (килешүләр) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыруда өченче затларның катнашу тәртибен билгели торган алдан шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе (булганда).

11. Сәнәгать продукциясе җитештерүе үзләштерелә торган махсус инвестиция контракты төзү өчен инвестор әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән бергә гариза составында инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында җирлектә аналоглары булмаган сәнәгать продукциясе җитештерүе үзләштерелүен раслаучы документлар һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында алдан килешү (килешүләр) яисә шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе тапшыра (булганда).

12. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге белгечләре Арча муниципаль районының Инвестиция советы белән берлектә әлеге Тәртипнең 8-11 пунктларында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә кергән гаризаны теркиләр:

- үз компетенциясе кысаларында алынган документларны карыйлар;

- махсус инвестиция контракты төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерлиләр, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Сәнәгатьнең аерым тармаклары өчен махсус инвестиция контрактлары турында" 2015 елның 16 июлендәге 708 номерлы карары белән расланган типик форма буенча вәкаләтле орган төзегән махсус инвестиция контракты проектын Арча муниципаль районының инвестиция советына җибәрәләр.

13. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (булган очракта) махсус инвестиция контракты проекты алганнан соң 10 эш көне эчендә Арча муниципаль районы Урта Курса Башкарма комитет җитәкчесенә махсус инвестиция контрактына кул кую яисә махсус инвестиция контрактына кул куюдан баш тарту турында язмача хәбәр җибәрәләр.

14. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (булган очракта) тарафыннан кул куелган инвестиция контракты алынганнан соң 10 эш көне эчендә, ә инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка карата муниципаль хокукый актларда каралган кызыксындыру чаралары гамәлгә ашырылган очракта, Арча муниципаль районы Урта Курса Башкарма комитеты махсус инвестиция контрактына кул куя.

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлегендә
махсус инвестиция контракты
төзү тәртибе турында Нигезләмәгә
1 нче кушымта

**Инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонт ясауга һәм төзелешне тәмамлауга инвестиция контракты төзүгә гариза (юридик зат өчен)**

1. Инвестиция контракты объекты:
1.1. Объектның тулы исеме ____________________________________
1.2. Объектның адресы ____________________________________________________
1.3. Милек: ___________________________________________________
1.4. Баланс тотучы________________________________________________
1.5. Объектның кыскача тасвирламасы______________________________
2. Инвестор (юридик зат):
2.1. Тулы исеме _____________________________________________
2.2. Урнашу урыны _________________________________________________
2.3. Оештыру-хокукый формасы ___________________________________
2.4. Дәүләт теркәве номеры һәм датасы _________________________
2.5. Банк реквизитлары ____________________________________________
3. Инвестиция контракты буенча төп тәкъдимнәр:
3.1. Төзелеш, реставрация эшләре буенча планлаштырылган төп эшләр, объектны реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки төзү инвестицияләү

_________________________________________________________________________

3.2. Инвестицияләр кертү вакыты буенча планлаштырылган инвестицияләр күләме

_________________________________________________________________________

____________________ ____________________ ____________________________

(вазыйфасы, ФИАИ) (имза, дата)

М.У.

(Инвестиция контракты төзүгә гариза имзалау хокукын раслый торган документның исеме, номеры һәм датасы)

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлегендә
махсус инвестиция контракты
төзү тәртибе турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонт ясауга һәм төзелешне тәмамлауга инвестиция контракты төзүгә гариза (физик зат өчен)**

1. Инвестиция контракты объекты:
1.1. Объектның тулы исеме ______________________________
1.2. Объектның адресы ________________________________________
1.3. Милек: __________________________________________
1.4.Баланс тотучы________________________________________
1.5. Объектның кыскача характеристикасы _____________________________
2. Инвестор (физик зат - шәхси эшмәкәр):
2.1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ___________________________________
2.2. Паспорт мәгълүматлары: серия _________ N _______________,
кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән___________________________________________
2.3. Яшәү урыны адресы ___________________________________
2.4. Дәүләт теркәве турында таныклык __________________
2.5. Исәп-хисап счеты номеры ____________________________________
3. Инвестиция контракты буенча төп тәкъдимнәр:
3.1. Төзелеш, реставрация эшләре буенча планлаштырылган төп эшләр, объектны реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки төзү инвестицияләү
__________________________________________________________

3.2. Инвестицияләр кертү вакыты буенча планлаштырылган инвестицияләр күләме _____________

________________________ _______________ __________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза, дата)
(Инвестиция контракты төзүгә гариза имзалау хокукын раслый торган документның исеме, номеры һәм датасы)

Арча муниципаль районы
Урта Курса авыл җирлегендә
махсус инвестиция контракты
төзү тәртибе турында Нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Инвестицион контракт кысаларында инвестицияләү объектын төзү, реставрацияләү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки төзелеш эшләрен тәмамлау буенча инвестиция программасы**

Әлеге программаның максаты - инвестицияләү объектын төзүгә, реставрацияләүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга яки төзүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген билгеләү. Төзелеш, реставрация, реконструкция, капиталь ремонт яисә төзелеп беткәннән соң объектны билгеләү планлаштырыла:
______________________________________________________________

Объектның характеристикасы һәм техник торышы:
______________________________________________________________

Инвестиция контракты кысаларында планлаштырылган эшләр, сроклар һәм чыгымнар:
______________________________________________________________

Инвестиция контракты якларының тәкъдим ителә торган мөлкәт хокуклары күләме инвестиция проектын тормышка ашыру нәтиҗәләре (нигезләп):
баланс тотучы - ___________________;
инвестор - ____________________________.

1. Планлаштырылган эшләргә башлангыч сметалар.
2. Объектта төзелешне тәмамлау буенча план-график.